# Бер гомер аз...

Ул гаиләдә бердәнбер бала иде. Әти-әнисе аны үлеп көтте. 8 ел аларның гаиләсендә бала тавышы яңгыравын, кычкырып-кычкырып елавын, шатлыклы көлүен көтеп зарыгып беттеләр. Һәм, ниһаять, Шакир белән Гөлфия улларын кочакларына алып, үзләре үк шатлыкларын кая куя белмичә, елап җибәрделәр. Шакир ир кеше буларак, бар көчен җыеп, күз яшьләрен күрсәтмәскә тырышты. Вакыт-вакыт күз төпләрен сөрткәләп кенә торды. Сөйгән хатыны Гөлфия исә күңелдәге бәхет һәм шатлык ташкыннарын тыя алмады, тыярга теләмәде дә кебек. Яңгыр тамчылары хәтле күз яшьләреннән күлмәкләре чыланып беткән иде. Әйе, озак, бик озак көткәннәр иде алар Раян (улларына шул исемне сайладылар; бу исем инде 7-8 ел элек сайланган булып, кире уйларга урын калмаган иде).

Раян дөньяга килгән көн искиткеч җылы, кояшлы иде. Ара-тирә ягымлы җил тәрәзәдән кереп, Гөлфиянең тирләгән битләрен, төне буе киерелеп чыккан тәненнән ... китә шикелле. Ул сулыш ала да тагын көчәнә. Янындагы туташлары аңа көч биреп тордылар. Шул рәвешле Раян шушы якты дөньяга килде. Зур авырлыклар белән тапса да, әнисе өчен хәзер барысы да бер мизгел кебек кенә тоелды. Ул 9 ай дәвамында токсикоз белән интеккәнен дә, сулары киткәндә өйдә берүзе калып, көч-хәл белән ашыгыч ярдәм машинасын чакырганын, ярымкараңгылыкта күргән күзләре белән табибларга ишек ачканын да, ике көн тулгаклар белән хәлсезләнеп ятканын да онытты. “Сигез ел, сигез... көттем сине, улым” дигән уй белән тәмле йокыга талды.

Шакир бик теләмәсә дә бу юлы да командировкага китәргә мәҗбүр булды. Эшендә үз эшен инәсе кадәр белүче бер ул гына. Шуңа идарә башлыгы андый җаваплы командировкаларга бары аны гына юллый иде. Каршы килеп тә булмый. Хатынының бала табар вакыты җитүенә карамастан, аны Иркутск шәһәренә бик тә мөһим сөйләшүләр ике атнага ук җибәрделәр. Китәргә бер дә теләмәде ул. Сөйгәнен дә шушы аеруча әһәмиятле вакытта калдырырга теләмәде. Әмма җаваплы һәм бигрәк тә әдәпле кеше булганлыктан, Шакир кырт кисеп “юк” дип җавап бирергә кыймады. Әмма бары үзенекен итте: бала туасы көнгә бар авырлыкларны кичеп кайтып җитте.

Менә алар өчесе бергә өйдә. Бу көнне бәхетле ата-ана күбрәк бала янында үткәрергә теләделәр. Бер-бер артлы чүпрәкләрен алыштырдылар, кулдан да төшермәделәр. Икесе дә бала исенә исереп, бәхеттән исереп йөрделәр. Көне буена аякта уздырсалар да, арыганлыкларын сизмәделәр. Бергәләп фотога төштеләр. Әмма, ни кызганыч, бу – аларның беренче һәм соңгы бәхет көне иде.

Тормыш бит ул бик кызык. Бер караганда, бәхетне ташып бирә, икенче караганда, шуны ук артыгы белән, үзеңә тамчысын да калдырмыйча тартып та ала. Уттан суга, судан чүлгә ташлый. Шул мизгелләрдә башкаларга карыйсың да, “эх, нинди бәхетле кешеләр бар; миңа аларның бер кечкенә өлеш бәхетен бирсәң иде, Ходай!”, дип ялварасың. Әмма һәр кешенең язмыш биргән үз бәхете һәм үз сынаулары була. Халыкта “Ходай һәр кешегә ул күтәрә алган кыенлыкларны гына бирә” дигән ышану яши. Бу гаиләгә шулкадәр авырлык күтәрергә язган микән, әллә очраклы ялгышлыклар нәтиҗәсеме... Әмма алда аларны зур сынаулар көтте.

Раянга 6 ай тулды дигәндә кинәт атасы авырып китте. Башта ул ютәл генә иде кебек. Аңа зур игътибар бирмәделәр. Игътибар бирергә вакыт та булмады бит. Бер яктан кечкенә бала, икенче яктан җаваплы эше. Барысына да өлгерергә, үз вазифаларыңны тиешле дәрәҗәдә үтәргә кирәк дип санады Шакир. Бераздан аның температурасы күтәрелде. Әмма эшен калдырмады, бер-ике көнгә ял да алмады. Дарулар эчеп, вакытлыча температураны төшереп йөри торган булды. Ә менә бүген ул яткан җиреннән тора алмады. Температурасы 40 градуска күтәрелгән. Гөлфия ашыгыч ярдәм машинасын чакырырга булды. Шакирның сүз әйтергә дә хәле юк. Ул ыңгыраша, саташып та ала. Ашыгыч ярдәм машинасы Шакирны хастаханәгә алып китте. Ходайга шөкер, бу авыруны алар исән-сау үткәреп җибәрделәр. Вакытында дәваларга өлгерделәр. Атна ун көн Шакир хастаханәдә ятып чыкты. Инде элеккеге халәтенә кайтты шикелле.

Ике ай вакыт үтеп тә китте. Бала инде тәпи йөри башлады, беренче сүзләрен дә әйтергә маташа. Аның эчкерсез елмаюыннан, бар фатирны яңгыратып көлүе һәм хәтта төн йоклатмый елавы да – барысы да күңелгә кереп бара, бераз күрми торсаң, сагындырта да башлый. Шакир эштә вакытта мөмкинчелеге булган саен өенә шалтырата, якыннарының хәлләрен белеп тора. Телефон аша гына булса да, сөйгән улының тавышын ишеттерергә дип хатыннан Раянга телефон трубкасын бирергә сорый. Шулай итеп, эш турында да онытып җибәрә. Аны хезмәттәшләре утырышка эзләп кергән чаклар да әз булмады. Улының тавышын ишетү дә Шакирның кәефләрен күтәреп җибәрә, эштә булган авырлыклар да чүп булып кына күренә.

Шакир улын үлеп яратты. Улы өчен җирне әйләндереп куярга да әзер иде. 90 нчы еллар илдә авыр еллар булды. Акчасызлык, эшсезлек кебек күренешләр илкүләм бәлага әверелде. Әмма Шакир үз эш урынын саклап кала алды. Эш хакы күпкә кимесә дә, гаиләсен бернәрсәдә дә чикләмәде. Башкаларда булмаган кием, уенчык, ашамлык аларның гаиләсеннән аерылмады. Шуңа күрә Шакирга көн дә, төн дә эшләргә туры килде. Төн уртасында хәл итәсе сорау бар дип шалтыратсалар, шунда ук торып чабарга әзер. Эшне дә югалтырга ярамый, гаилә өчен үзәк өзелә, илдә дә авыр чак...

Шулар барысы да һәм башка бик күп кенә калган вак борчылулар йөрәккә бәрми калмый. Һәм күрәсең, шуларның нәтиҗәсе булып, көннәрдән беркөнне Гөлиягә хастаханәдән шалтырау килде. Шәфкать туташы Шакирның хастаханәгә эләгүе, аннан да ары комада булуы турында хәбәр итте. Гөлиянең күзләре караңгыланып китте, торган җиреннән стена буйлап идәнгә шуышып төште. Башы чыңлый, әйләнә, уйлары буталып бетте. Нишләргә? Кая барырга? һәм башка бик күп сораулар башында чуалды. Баласын күрше Бибинур апага калдырып, тизрәк хастаханәгә чапты.

Хастаханәдә аны Шакирны дәвалаучы табиб кабул итте. Хәленең авыр, комадан чыгуы да бик зур сорау астында булуын сөйләп бирде. Гөлфия нишләргә белмәде. Дөресен генә әйткәндә, гаилә корылганнан бирле аңа мондый кыенлыклар белән очрашырга туры килмәде. Шуңа күрә бу мизгелдә югалып калды. Елады да елады.

Ул көне буе хастаханә коридорын саклады. Комада ятучы ире янына кертмәделәр, әмма аннан ерак та китә алмады. Кичен генә баласы янына кайта һәм арыганлыгы белән төннең ничек үтеп китүен дә сизмичә, тагын ире янына ашыга. Шулай итеп, бер атна узды. Атна үтеп китте дигәндә, һич көтелмәгән сүз: “Ирегез үлде...” Ә соңыннан: “Сәламәтлеге бу авыр сынауны күтәрә алмады... Иммунитеты каршы торырлык булмаган...” – дигән аңлатуларны Гөлия инде ишетмәде.

Тормышның бер мизгелдә кырт киселүе турында Гөлия беркайчан уйламаган иде. Ә шулай була ала икән. Бер мизгелдә тормышның мәгънәсе югала, син үзеңне бу тормышта яраксыз икәнлегеңә төшенәсең. Хәзер ничек тормыш итәргә соң? Бер караганда, җавабы да бар, әмма әлеге моментта Гөлия өчен аңа җавап бирү һич мөмкин түгел иде...

Тормыш бит ул яз көне тулы күкрәге белән сулыш алган, кышкы салкыннарның тоткынынннан азат ителгәннән соң, үзенең бар көчен күрсәтергә теләгән сулар шикелле. Язмыш аны нинди генә богауларга чорнамасын, ул барыбер ташып чыга, яшәү көче белән тулып, алга атлавын дәвам итә.

Гөлия дә яшәргә мәҗбүр булды. Әйе, нәкъ менә мәҗбүр. Чөнки Шакир вафат булганнан соң, аның тормышы яшәү түгел, ә исән калырга тырышуга әверелде. Матур гына яшәп яткан урыннан кискен караңгылыкка чум инде! Ә Гөлия өчен сөйгәненең үлеме караңгылык, юклык белән бер иде. Беренчедән, Шакир Гөлиянең беренче, саф мәхәббәте булды. Ул Шакирны күңеленең иң нечкә кылларын тибрәндереп яратты. Аның әйткән һәр сүзенә, һәр эшенә, үз-үзен горур тотышына, тормыш алып барырдай сыйфатлары булуына һәр көн сокланып яшәде. Шакир Гөлия өчен чын мәгънәсендә ир-ат идеалына

әверелде. Ул үзе дә ире өчен камил хатын, уңган хуҗабикә булырга тырышты...

Шакир үлгәннән соң, баштагы мәлдә Гөлфиягә, аның кечкенә улына бик авырга туры килде. Эшсезлек, һөнәр өлкәсендә тәҗрибәсезлек, илдәге сәяси һәм икътисади хәлнең көннән-көн түбәнлеккә төшә баруы – барысы да чүп өстенә чүмәлә кебек өелә барды. Эшкә урнашканчы, Гөлиягә өендәге күп кенә кыймматле әйберләрне базарга алып чыгып очсызга сатып җибәрергә мәҗбүр булды. Аны эшкә алырга ашыкмадылар. Ире үлгәннән соң, күп кенә танышлары да аннан баш тарттылар. Күрәсең, дуслыклары да шулкадәр генә булгандыр. Әмма берчын дус барыбер була бит ул. Аларның гаилә дуслары – Нәзирә Гөлияне авыр хәлдә калдырмады. Үзенә эшкә алды. Менә хәзер Гөлия шәһәр базарында сатучы булып эшли.

Эшкә кулы уңган булса да, мондый эшнең асылларын ул әле белми иде. Базарда яхшы сату өчен, хөр телле, юкны бар дип, барны юк итеп чыгара белергә кирәк. Гөлия моңа һич кенә дә күнекмәгән. Очсызлы товарны затлы дип сату аның күңелен китә. Шул сәбәпле баштагы мәлдә эше бармый интекте. Әмма татар халкы юктан гына “Нужа печән ашата” димәгән, белеп сөйләгән борынгылар. Менә Гөлфия дә сату эшенең серләренә төшенде, үзенең күп кенә тормыш принципларын таптап китәргә мәҗбүр булды. Гөлия моңа кадәр хуҗабикә булып кына яшәсә дә, кирәгенә бик тиз өйрәнде. Үзенең сатуга сәләте дә юк түгел. Моңарчы яшеренеп яткан талантлары хәзер үзләрен чын-чынлап күрсәтергә мөмкинлек алдылар. Тора-бара Гөлия дусты Нәзирәнең уң кулына әверелде. Көндез базарда сату итсә, төштән соң кәгазь эшләре белән утыра башлады. Нәзирәгә күп кенә сорауларга җавап табарга булышты.

Тормыш бара, елга ташкыны туктап калмый...

Менә инде улы Раян да үсеп җитте. Мәктәпне тәмамлады. Әтисенә ошап, озын буйлы, киң җилкәле, шомырт күзле, куе кара чәчле егет булып өлгерде ул. Раян характеры буенча да әтисенә ошаган иде. Көчле рухлы, һәрвакыт дөреслек ягында, саф күңелле, үзе дусларына һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер. Шул сыйфатлары өчен аны мәктәптәге дуслары да, танышлары да яраталар һәм хөрмәт итәләр. Әтисе шикелле баянда шәп уйный. Монысына музыка мәктәбендә өйрәнсә, гитарада уйнарга үзлегеннән өйрәнде. Шуның белән ул һәр кичәнең үзенчәлеге булып торды.

Әнисе Раян өчен барын табарга, барын эшләргә әзер торды. Мәктәптә укыганда, бар кирәк-ярагы табылды, өс-башы һәрвакыт менә дигән каралган. Моннан тыш, ул музыка мәктәбенә йөрде, көрәш секциясен ташламады. Үзегез аңлыйсыз, 90 нчы елларда, ирсез хатынга тормыш алып бару искиткеч авыр булды. Әмма Гөлфия көн-төн эшләп, улы өчен бар кирәген артыгы

белән кайтара иде. Тик болар барысы да тормышның ялтыравыгы, өске тышлыгы гына бит. Ә тормышта иң мөһиме ул – бер-береңне аңлау, ишетеп яшәү, назыңны бирү, сөю һәм сөелү. Шуларның күбесен Раян, кызганычка каршы, әнисеннән күрмәде. Юк, дөресен әйтик, Гөлфия вакыты булу белән улы янына ашыкты. Мөмкинлек чыгу белән вакытын аңа бирергә омтылды. Ләкин бу әз, бик әз иде... Раян да әнисен аңларга тырышты. Эше күп шул. Үзе җаваплы да. Бары мәктәптә, музыка мәктәбендә, төрле конкурсларда чыгыш ясаганда, башка ата-аналарның балалары өчен җан атып утырулары гына күңелне тырмалап ала иде. Шундый кичәләрнең берсеннән Раян бик әрнеп кайтты. Өйгә керүгә үк кулындагы бар нәрсәсен бүлмә уртасына очырып җибәрде дә, үз бүлмәсенә кереп китте. Әнисе аптыравыннан нишләргә белмәде. Бүлмә ишеге янына килеп туктады, тын гына тыңлап торды. Ә ишек аркылы ап-ачык булып, улының үксеп-үксеп елавы ишетелде. Гөлия гомерендә беренче тапкыр нишләргә белмәде. Керсәм, куып чыгарыр, дип уйлады. Бераз вакыт узганнан соң, елау тавышлары тынды. Гөлия улы янына кергәндә, ул чалкан ятып түшәмгә текәлгән иде. Әкрен адымнар белән улы янына килеп утырды. Бу мәлдә ул аңа нәрсә дип эндәшергә дә белмәде.

- Ни булды, улым? – дип кенә әйтә алды ул ярым калтыраган тавыш белән.

Тынлык дәвам итте. Аны беренче булып Раян үзе бозды:

- Әни... Әни, нигә син мине башка әниләр шикелле бер дә кочакламыйсың, мине башка әниләр шикелле үпмисең?.. Син мине яратмыйсыңмы? – диде. Аның соңгы җөмләсе башкаларыннан үзенең ышанычлы яңгыравы белән аерылып торды.

- Улым... – Гөлфиянең тавышы калтырый иде. – Син нәрсә сөйлисең? Ничек яратмыйм инде. Син бит минем бердәнбер балам, минем күз нурым, минем киләчәгем, минем ышанычым, - диеп улын юатырга тырышса да, үз тавышының ышанычсыз булып яңгыравын бик яхшы аңлады.

- Әни...Әнием...Мин бит сине бик тә яратам, - диде дә Раян, әнисен бар көче белән кочаклап алды.

Тагы да югалып калган Гөлия дә улын кочты һәм елап җибәрде. Бу кичтә алар икесе дә ачылып сөйләштеләр, бер-берсен аңлаштылар. Һәм шул кичтән, шул сөйләшүдән соң Раян үзенә башка еламаска, ә киресенчә, мөмкин булганча әнисенә ярдәм итәргә, аны тәүлек буена диярлек сузылган эшеннән азат итәргә, күп итеп акча эшләргә һәм әнисенең дә, үзенең дә акча мохтаҗлыгыннан азат булырга сүз бирде. Әйе, максатлар зурдан иде. Әмма ул үз-үзендә шулкадәр ышанган иде, куйган максатларына ирешәчәгенә бер дә шикләнмәде.

Һәм менә хәзер ул - Казан дәүләт университетының 1 курс студенты. Раян мәктәпне алтын медальгә тәмамлады һәм шул рәвешле университетка бер генә имтиханны биреп керү мөмкинлегеннән файдаланды.

Группадашлары белән бик тиз арада уртак тел тапты. Аны хәтта группа старостасы итеп сайлап куйдылар. Һәм башланды ыгы-зыгылы, искиткеч мавыктыргыч студент тормышы. Хәзер инде Раян үзе өйгә кичен генә кайтып керә. Телендә һәрвакыт укыйсы фәннәр, укытучылар, группадашлары, ә аеруча ул яратып группадашы Миләүшә турында сөйли. Аның нәрсә кигәненнән алып университет ашханәсендә нәрсә алып ашаганына кадәр җентекләп бәян итә.

Әнисе улына сокланып карый. Ул инде хәзер шундый олы, шундый җитди һәм шул ук вакытта балаларча сөйкемле. Әйтерсең лә, Гөлфия әле генә улын ача башлады, аның шәхесенә төшенә барды. Инде 18 яшьлек ир-егет булып җиткәнен бик яхшы аңласа да, нәкъ менә бу моментларда аны битеннән сөясе килә иде. Ә көннәрдән бер көнне Раян аңа Миләүшә белән очраша башлауларын сөйләп бирде. Гашыйкларның кич буе бергә утырулары, өй эшләрен эшләүләре, зачет-имтиханнарга әзерләнүләре, урамда йөрүләреннән кайтуын инде Гөлфия зарыгып көтә башлады. Тәрәзә янында сәгатьләр буе торган чаклары да булмый калмады.

Шундый кичләрнең берсе иде. Раян группадашлары белән бөтен университет күләмендә кичә оештырды. Шул кичәдән соң группадашы Айратның фатирына барып утырдылар. Ул гитарада уйнады, Миләүшәсе кушылып җырлады, башкалар сокланып карап тордылар. Вакытның ничек узганын да сизми калдылар. Миләүшәне озатып кайтканда, инде иртәнге сәгать дүрт иде. Өйгә песи шикелле керде, диванда йоклап ятучы әнисен күрде. Әнисе шәлен генә ябынып яткан, төне буе көткән улын һәм көткән җиреннән йоклап та киткән, күрәсең.

Раян әнисе янына килеп, әкрен генә өстенә япты, маңгаеннан үбеп алды. Үзе дә шаккатты: бары бүген генә ул әнисенең күз янындагы җыерчыкларының тирәнлеген күрде һәм шуннан аптырап куйды. “Әнисенең якты йөзен ямьсезли торган шундый тирән җырчыклар кайчан барлыкка килгән? Һәм нигә мин аларны элегрәк күрмәгәнмен?” дип уйлады ул. Әмма җавабын таба алмады.

Үз бүлмәсенә кереп китәргә җыенганда, күзенә нидер чалынып китте. Диван янында бер конверт ята икән. Иелеп карады, күңелен кызыксыну биләп алды. Конверт ачык. Алыргамы, укыргамы? Бер яктан кызык та, икенче яктан, әнисе аны кечкенә чагыннан ук кеше әйберенә тияргә ярамый дип өйрәтте. Әмма конверт тышында алучы урынына әнисенең исеме язылуы, ә җибәрүче итеп аңа таныш булмаган Фәрит Ногманов булуы, әйтерсең лә аның шикләнүен сызып атты һәм ул конвертны ачып карарга уйлады. Иң беренче булып, аның кул астына фото төште. Фотода аның әнисе һәм бер ир төшкән. Әмма бу ирне Раян беренче тапкыр күрә. Моңа кадәр бер дә чалынмаган бу ир Раянның йөрәгендә шик уятты. Аның кем булуы, әнисе белән кочаклашып фотга төшүе, фотоның аерым конвертта килүе – барысы да хәзер ачыкланырга тиеш.

Раян, ашыгып, үз бүлмәсенә чыгып китте. Әнисе ваемсыз йоклавын дәвам итте. Бүлмәсенә керү белән конверттагы булганнарны алып караватына куйды. Фотодан тыш анда тагын ике биткә язылган хат салынган иде. Раян дикъкать белән хатны укырга кереште. Ул хатның бер генә сүзен төшереп калырга теләмичә, ашыкмыйча, туктый-туктый укыды...укыды...укыды да... Юк, булмас, бу минем әнием турында була алмый. Ничек алай? Кем син Гөлфия?

Хатны язган кеше – Фәрит Ногманов. Ул аның әнисен ярата. Аңа элеккеге мөнәсәбәтләрне кире кайтарырга теләве турында сөйли. Гөлфияне сагынуын, аның ризалыгыналу белән гаиләсеннән китәчәге хакында тәфсилләп язган.

Раян хат текстын берничә тапкыр укыса да, күп кенә нәрсәләргә төшенә алмады. Бу хат авторына ышансаң, димәк, аны әнисе беркем белән дә очрашмыйм, әтиеңнән башка беркемне яратмыйм дип ышандырулары ялган булган?

Раянның әнисенең сүзләреннән бер дә шикләнәсе килмәде. Якын кешесенә дә ышана алмаса, бу тормышта тагын кемгә таянырга, ышанырга кала соң инде?! Газиз әниең дә ялганласа, бу дөньяда чынлык бармы соң ул? Төне буеннан алган бар уңай хисләре каядыр эзсез югалды. Күңелне борчу биләп алды. Раянның башында бер генә уй чуалды: оятсыз Фәрит Ногмановны табарга да бар ачу белән йөзенә тондырырга. "Әни хакында болай язарга, аның чиста исемен яманларга ни хакы бар аның? Табам, бүген үк табам да әйтергә теләгәнемне йөзенә бәреп әйтәм!"- дип уйлады Раян һәм рюкзагын җыеп чыгып та китте. Ишектән чыкканда, ул тагын бер тапкыр әнисенә текәлеп карады. Хәзерге моментта ул шундый самими, шундый матур иде... Күрәсең, бүген генә әнисенең нинди матур, сөйкемле булуын аңларга язган иде. Раян бары шушы моментта гына әнисен ничек яратуын аңлады. Ул аны һәрвакыт яклар,беркемнән начар сүз әйттермәс, гомер буе янында үткәрер иде. Менә шул оятсызны күреп, йөзен канга гына батырам да кайтам, кайтам,әнкәй, дип уйлады ул һәм елмаеп куйды. Кайтам һәм беркайчан да ташламам.

Әмма бу аларның соңгы күрешүе булуын икесенең берсе дә әле белми иде.

Гөлфиянең күз янындагы ике тирән җыерчыгы гына аның томышта күргәннәре хакында сөйли алды...

Раян хатта бирелгән адрес буенча юл тотты. Кесәсендә булган акчасына Казанга кадәр автобуска билет алды. Автобуста барганда, ул шул оятсызга әйтәсе сүзләрен барлады, бар ачуын җыеп барды. Әмма күпмедер вакыт үткәннән соң, төне буе йокламаганлык үзен сиздерде һәм Раян татлы йокыга талды. Аны автобус йөртүченең салонга: "Уян, малай! Килеп җиттек! Юл буе йокы симерттең бит инде!" – дип кычкыруы уятты.

Менә Раян Казан урамнарын айкый. Моңарчы ул мондый хозурлыкны әнисеннән, аның янына килгән дус-ишләреннән генә ишетеп белә иде. Эш

белән аларга калада күпләп булырга туры килде. Ә менә хәзер ул үзе монда. Өйгә кайту белән әнисенә тәкъдим ясаячак ул: Казанга күчәргә, Казанда яшәргә. Ул укуын монда дәвам итәр, әнисенә дә эш табылыр, шөкер. Шул уйларга чумып, үзенең кая барып чыкканын да сизми калган. Якын тирәгедәгеләрдән ул хатта язылган урамны, йортны ничек табарга кирәклеген белеп, хәзер юлын шунда тотты.

Ул барып чыккан йорт шәхси йорт булып чыкты. Олы йорт, кирпечтән салынган, җитмәсә ике катлы. Һәр ягында зур-зур тәрәзәләр, тәрәзәләрдә ап-ак челтәрләр, йорт тирәсендә берсеннән-берсе матур гөлләр, ул заманда беркемдә булмаган сыннар. Участокның икенче башында зур гараж салынган. Икеяклы капкасы ачык, машина кертелгән. Димәк, хуҗасы өйдә. Әмма Раян барыбер шикләнде: дөрес килде микән ул, әллә хатта ялгыш адрес бирелгәнме? Юк, булмас, әнисен үзенә чакырган кеше ялган адрес язып җибәрмәс. Менә йорт ишегеннән бер ханым чыкты. Ул җыештыручы хатынга ошаган иде. Раян аңа эндәшергә булды. Һәм ул ялгышмаган булып чыкты. Җаны-тәне белән сөймәүче Фәрит Ногманов монда яши икән. Аны башта кертмәделәр, рация аркылы  уңай җавап бирелгәннән соң гына, шкаф хәтле ике яшь егет аны өй эченә озаттылар.

Бай йорт җиһазлары белән тулган, зәвыклы һәм кыйммәтле әйберләрдән генә торган бу йортта Раян артык адым ясарга да курыкты. Аны бер бүлмәгә керттеләр. Бу – хуҗаның эш бүлмәсе.

10 минут тирәсе вакыт үтте һәм бүлмәгә озын буйлы, киң җилкәле, 40-55 яшьләрдәге ир керде. Чәчләре әле дә кара, бер бөртек ак чәче юк, буй-сыны төз, күрәсең, спорт белән шөгыльләнүен ташламаган. Аның ышанычлы атлавы, ныклы адымнар белән бүлмәгә керүе Раянның үз-үзенә ышанычын сындырды шикелле. Текәлеп каравы да яшүсмер егетне какшатты. Ул хәтта бер адым артка атлады һәм үзе шуннан оялып куйды. Фәрит эш өстәле янына барып басты, аңа сөялде һәм энәсеннән җебенә кадәр Раянны карап чыкты. Әйтерсең лә аңа үзенчә бәя бирде. Раян сөйләшүне үзе башлады, шул вакытта тавышының калтырап-калтырап китүен сизде:

- Мин – Раян Сафиллин. Гөлия Сафиуллинаның улы. Сез аны беләсез дип уйлыйм. Сездән килгән хатны үзегезгә тапшырырга килдем. Минем әниемә сезнең игътибарыгыз да, мәхәббәтегез дә, аннан артыгы акчагыз да кирәкми. Аның сөйгән кешесе бар. Ул минем әтием – Шакир Сафиуллин. Һәм ул аны беркайчан да, беркемгә дә  бернинди алтын тауларга да алыштырмаячак, - диде дә алдында торучыга хатны сузды.

Тик Фәрит хатны алырга ашыкмады. Ул борылып китте һәм өстәле артына утырды. Зур гына паузадан соң сүзен башлады:

- Син эшнең ни дәрәҗәдә тирәнгә киткәнен аңлап бетермисең ахры. Әниең монда килүеңне дә белми торгандыр? – һәм җавап бирергә мөмкинлек бирмичә дәвам итте – Хатта язылганнар барысы да хак. Синең әниең миңа

бик кадерле. Заманында ул минеке булмады, әмма хәзер ул минеке булачак. Теләсә дә, теләмәсә дә.

- Сез нәрсә сөйлисез! – үзенең тавышының бөтен бүлмәгә яңгыравыннан үзе дә куркып китте. – Аны әллә берәр товар дип беләсезме? Ул - тере кеше, аның үз фикере, үз сайлау мөмкинлеге бар! Ә безнең тормышка катышырга мин сезгә ирек бирмәм. Үзегезне кем дип белдегез соң сез?!

Фәрит өчен Раян яшь, тәҗрибәсез бер маңка малай иде. Заманында андыйларны ул бер карашы белән урыннарына утырта торган булды. Әмма бу егеттә ул ниндидер көчле үзәк булуын тоемлады. Тик юл бирергә бер дә теләмәде:

- Син минем кем икәнемне белмисең шул. Әниең сиңа минем турында ниләр әйтте?

- Сезнең кем булуыгыз миңа мөһим түгел, безнең тормышка катышмагыз дип әйтергә генә килдем.

- Катышыргамы юкмы, анысын мин үзем хәл итәрмен, ә әниең үзе хәл итәр. Заманында синнән рөхсәт сорауны кирәк тапмады бит.

- Нәрсә сөйлисез сез? Нинди заманында?

- Их, син, маңка малай. Берни белми торып, монда килеп, әле миңа тавыш күтәреп маташасыңмы? Ярар, белеп тор алайса: без синең әниең белән 10 ел очраштык, ул минем сөяркәм иде. Нәзирә әниеңне эшкә урнаштырды, шуның аркылы таныштык. Мин...хм... Нәзирәнең бизнес буенча ярдәмчесе, дусты идем. Ә әниеңә тормыш алып барырга, сине үстерергә акча кирәк иде. Аңлыйсыңдыр, тол хатынга бер дә җиңел булмады ул елларда. Ә минем ярдәм итәргә мөмкинчелегем дә, теләгем дә бар иде, - диде ул Раянга җавап биреп.

Яңа гына алынган мондый мәгълүматтан, барыннан бигрәк “сөяркә” дигән сүздән Раянның аягы астында җир убылган шикелле булды. Әнисенең исемен таплап маташкан бу кешенең йөзенә бәрәсе килде. Куллары да йомарланды. Әллә шуны сизеп, Фәрит сүзен дәвам итте:

- Син инде олы кеше, ялгышмасам, институтта укыйсың. Аңларга тиешсең, ана кеше баласы өчен барысына барырга әзер була. Ә әниең сине бик ярата. Мин аңа тәкъдим ясагач, аны кире какмады.

- Нигә башта ук аны хатыныгыз итмәдегез? Нигә хәзер генә аңа язарга булдыгыз? – диде Раян түземлеген югалтып.

Өстәл артыннан торып чыкты да Фәрит янәдән Раян каршысына чыкты, аякларын кушырып өстәлгә сөялде. Кулларын да күкрәгенә куеп сүзен дәвам итте:

- Бу бары безнең икебезгә генә кагыла. Шулай да инде синең зур юл ясавың буш булмасын өчен шуны әйтим: ул вакытта мин инде өйләнгән идем, хатыным беренче балабызны көтә иде. Карьера ясыйсым бар иде, ә хатынымның әтисе миңа монда бик булышты. Шуның ярдәме белән мин эш баскычыннан менә башладым һәм менә бүгенге көндә мин – Ногманов Фәрит

Абдулла улы – Казан шәһәренең Автозавод районы милиция башлыгы. Генерал-майор дәрәҗәсенә ирештем. Юк, мин хатынымны ташлап китә алмадым... Тик хәзер, Лераның әтисе вафат булу белән, мин үземә үзем хуҗа, ниһаять, ничә елдан соң үзем теләгәнне эшләргә мөмкинмен. Мин ирекле! – диде Фәрит соңгы сүзләренә аеруча нык басым ясап.

Үз әнисен кемнеңдер уенчыгы итеп тойды Раян. Ниндидер бер чит ир аның әнисен курчак урынына тота: теләсә үзенә тарта, теләсә куып җибәрә. Раян да урыныннан торды һәм соңгы сүзләрен әйтергә теләп:

- Юк инде, ул сезнең шәхси уенчыгыгыз түгел. Ул – кеше. Ул – минем әнием. Элегрәк аны якларга кеше булмаганга, сезнең кулларыгызга килеп кергән ул, әмма хәзер мин аны сезгә бирмәячәкмен. Шуны белеп торыгыз, безнең гаиләгә тыгыласы булмагыз! – диде Раян һәм кулындагы конвертны Фәрит ягына ташлап, борылып чыгып китәргә ашыкты. Әмма ике адым да ясарга өлгермәде, Фәриттән җавап алды. Фәритнең горур табигате моның дорфа адымына һичшиксез җавап бирергә тиеш иде:

- Син әллә анаңны фәрештә дип белдең? Бик ялгышасын маңка малай! Халык арасында акча өчен очрашкан хатыннарны кем дип йөрткәннәрен беләсеңме?

Әйтәсе сүзләре шул гына булмагандыр да Фәритнең, әмма Раян аның бу пычрагын тыңлап торырга җыенмый иде. Ул Фәрит ягына кинәт кенә борылды да бар көчен йодрыгына салып сугып та җибәрде. Ни дәрәҗәдә көчле булгандыр бу сугу, тик Фәрит торган җиреннән стена ягында торган диван янына очып барып төште. Башы белән диван почмагына бәрелде. Раян үзе дә моны көтмәде кебек, шулай да кыюлыгын җуймыйча, идәндә яткан Фәрит янына барып:

- Безгә тыгыласы булма! – диде дә тиз адымнар белән чыгып китте.

Раянның саф һавага чыгу белән башлары әйләнеп китте. Күпме пычрак ишетте ул бу ярты сәгать эчендә. Фәритнең сүзләренә аның бер тамчы да ышанасы килмәде. Ул бик ачулы иде. Ә менә кемгә күбрәк ачулы булуын үзе дә төшенә алмады: әллә пычрак түккән Фәриткәме, әллә аны 10 ел буе алдаган әнисенәме.

Бервакыт Раян ачуыннан айныды һәм яңадан өенә кайтырга кирәклеген аңлап, үтеп баручылардан вокзалга юлны сорады һәм аңа баручы автобуска утырып китте.

Үз тукталышында төшүе булды, шунда ук аны ике яктан милиция хезмәткәрләре богаулап алдылар һәм бернәрсә аңлатмыйча, милиция бүлегенә алып килделәр. Эшнең нәрсәдә икәненә Раян бик тиз төшенде. Аны алып килгән милиция бүлегендә аңа авыз да ачтырмадылар. Әнисенә шалтыратырга сорагач та “авызыңны йомып утыр, селкенәсе дә булма” диделәр.

Төнлеккә аны аерым бер бүлмәгә кертеп эт урынына кыйнадылар. Биткә сукмадылар, эчкә, аркага аяк белән һәм кул астына эләккән нәрсәләр белән

тукмадылар. Иртәнгә күкрәк турысыннан аякларына кадәр карарлык түгел иде. Бер сантиметр тере җире калмаган, кара көйгән иде. Бер-ике көн хәленә килгәннән соң, аның янына Фәрит үзе килде. Аның да уң күзе төбендә теге сөйләшүдән калган кара эз бар. Әмма Раянга шатланырга урын юк иде, чөнки:

- Миңа кул күтәрергә җөрьәт иттең. Дөреслек яратасыңмы? Менә тикшереп карарбыз. Иртәгәдән син Чечняга Басаев отрядларына каршы сугышырга, Россиянең башка уллары белән беррәттән җибәреләсең. Батыр бул, әниеңнең йөзенә кызыллык китермә, - диде Фәрит, елмаюын кырыслыгы артында яшерергә тырышып.

Фәритнең әйткәннәре буш куркыту гына булмады. Чыннан да аны иртә таңнан уятып, документларын кулына тоттырып, Мәскәүгә баручы, аның кебек үк яшь егетләр белән тулы автобуска утыртып җибәрделәр...

Менә ул Чечня республикасында. Менә ул инде 3 нче аен хезмәт итә. Иртәгә аларның отрядын бик җаваплы эшкә җибәрәчәкләр. Бер көн элек Грозный шәһәрендә разведкага барган хезмәттәшләре чечен сугышчысын тотканнар. Аның сүзләренә караганда боевикларның зур отряды Грозный шәһәренең бер йортында урнашкан һәм шунда шартлаткычлар әзерлиләр. Бу шартлаткычларны алар берничә көннән Дагестан белән граниөа зур терактка әзерлиләр имеш. Сүзләренә дә ышанмаслар иде, әмма шул йортка җибәрелгән махсус разведка, бу йортта чыннан да дистәдән артык сугышчының шартлаткыч әзерләүләрен расладылар.

Шул рәвешле аларның отрядына әлеге йорттагы сугышчыларны кулга алырга, шартлаткычларны базага алып кайтырга әмер бирелде. Вакыты иртәнге 4 кә билгеләнде. Раянның кичтән үк йокысы килмәде. Әнисеннән, Миләүшәсеннән килгән җылыхатларны әллә ничә тапкыр укып чыкты. Монда ничек эләгүе хакында ул аларның берсенә дә сөйләмәде. Исән-сау кайтып җиткәч сөйләрмен дип кенә сүз бирде. Задание алдыннан хат яза торган гадәте юк иде, әмма алдагы задание алдыннан нишләптер кул үзе каләмгә тартылды, сүзләр үзләреннән үзләре җөмлә барлыкка китерде. Ул сәгать эчендә ике хат язып өлгерде. Башкалар инде күптән йокыга киткән булсалар да, ул одеяло астында язган хатларын кат-кат укып чыкты. Хатларында икесен дә өзелеп сөюен, сагынуын, алардан башка уздырган минутның сәгатькә тиң булуын язды. Әнисенә ул аның иң якын кешесе икәнен ассызыклады. Аны үзен җәлләмичә, бар нәрсәсе булсын дип үстерүе өчен рәхмәт әйтте. Киләчәктә үзе үстергән улы өчен горурланачагына сүз бирде. Ә Миләүшәсенә көтмәсә, үпкәләмәячәген язды. Чөнки монда көн саен диярлек кеше үлә – я исламистлар ягыннан, я рус сугышчылары югалтулар кичерә. Кан һәм тир, тузан һәм пычрак белән камаланган җирдә йөргән кешенең кайтуын көтү зур көч һәм түземлелек сорый. Ә ул яшь, чибәр, уңган, булган кыз аны көтәргә тиешме? Юк, үпкәләмәс, ул Миләүшәне аңлар дип язды. Язды, тик шул сүзләренә үзе дә ышанмады.

Йокы озак кына килмәде. Менә бер заман ул аллы-гөлле чәчәкләр болынында. Аның каршысына әнисе чыга. Ул яшьләрен сөртә-сөртә аны кочаклап ала. Әнисе артыннан зур чәчәк бәйләме тоткан Миләүшә күренә. Алар чәчәкләр арасында йөгерешәләр, куышалар, кочаклашалар. Әнисе яшьләргә карап соклана. Кинәт кенә аңа икенче бер чит кеше чалынып китә. Бу – аның әтисе Шакир икән. Бәхетеннән шашып, әтисе янына чаба. Әмма шулай ук кинәт болытлар куера, каты җил чыга. Әтисенең сурәте ерагая бара. Раян аны куып тота алмый. Әтисенең сурәтен куе яшен болытлары юып төшерде. Барып җиттем дигәндә генә ул икенче берәүгә әйләнә. Дамир?! Раян шаккатып торып калды. Аяк асты убылды, Раян да кайдадыр төшеп китте.

Сискәнеп уянып китсә, янында торучы дусты Дамир аны уята икән. Вакыт җиткән. Аяк тартмый бүген. Һич торасы килми. Төше дә әллә нәрсә булды шунда, болай да борчулы күңелгә шом салды. Юынып, әзерләнеп беткәч, ике хатын хезмәттәшенә тапшырды, аларны хат ташучыга бирергә кушты. Әллә күңеле нидер сизенгәнгә, ул бу эшне хезмәттәше җилкәсенә салды.

Шулай итеп алар урында. Ике катлы йортны камауга алдылар. Әкренләп йорт эченә керә башладылар. Эчкәрәк кергән саен ныграк шикләндерә. Беренче кат буш булып чыкты. Икенче катка менергә боерык бирделәр. Йөрәк тибеше ешайганнан ешая бара. Тик әле яшиселәр бар дигән уй баш очыннан үтеп китте. Икенче кат буш иде. Беркем юк. Дошманнарның бу урында булып, тиз арада җыенып китүләре сизелә. Күп әйберләр, кораллар ташланып калган. Менә бүлмә уртасында өстәл,ә аның өстендә зур япма белән капланган нәрсәдер тора. Сугышчылар барысы да моңа зур шик белән карадылар. Бүлмәдә тынлык урнашты. Шул тынлыкта сәгать тыкылдавы ишетелде. Һәрберсенең йөрәк тибеше сәгать йөрешен ун тапкырга уза шикелле.

Өлкән лейтенант Прохоров үзе өстәл янына атлады. Һәм икенче бер мизгелдә япманы, бер почмагыннан тотып, кинәт кенә тартып төшерде. Солдатларның йөрәге инде типми, ә туктап калды. Чөнки өстәл өстендә зур гына шартлаткыч ясап калдырылган һәм шартлауга кадәр 5 минут калып бара. Йорттан чыгарга әмер бирелде. Солдатлар чыгу ягына ашыктылар. Тик беренче йөгереп чыгучыны ук атып үтерделәр. Йортны төрле яклап дошманнар камап алганнар икән. Беркайдан да, бер яктан да чыгу юлы юк, бар юллар киселгән икән. Менә шулай Раян отряды засадага эләкте, ә иң куркынычы, монда калсаң да, чыгарга тырышсаң да, һәлак булачаксың.

Барысы да үз почмагында утыра, башлары иелгән, тирән уйга батып утыралар. Раян шуларга карап, нидер эшләргә кирәклеген аңлый. Озак та уйламады, ул хезмәттәшләренә тәкъдим итте: ул шартлаткычны өстенә киеп чыга, аның артыннан хезмәттәшләре чыга һәм дошманнар белән тигез сугыш башлый алалар. Барысы да эшнең нәрсә белән тәмамланачагын беләләр, әмма башка чара юк. Шулай эшләделәр.

Урамга чыкканда, Раян хезмәттәшләренә борылып карады. Аларның яшь тулы күзләрендә ул борчылу, сыкрану күрде. Әмма үзе елмаеп чыкты. Үзенең соңгы минутларын ул елмаеп каршы алды. Кояш нуры аның йөзенә төште, ә аның күз алдына ягымлы әнисе, сөйгәне Миләүшә килеп бастылар. Шартлау... Атыш башланды, кычкырыш, кан елгасы...

Сугыш бетте. Ул җиңү, дошманнарны юк итү белән тәмамланды. Шуңа да карамастан, солдатларның берсе дә елмаймый. Һәрберсе башын иеп, җирдә утыра. Беркем дә гадәттәгечә бер-берсен котламый, кочаклашмыйлар. Бу юлы җиңү аеруча кыйммәтле бәя белән алынды.

Раянның гәүдәсен туган ягына кайтардылар. Әнисе тулы бер гомергә картайган. Миләүшәнең йөзендә нур сүнгән. Раянны тиешлечә, бар кануннарга туры китереп күмделәр. Зиратка килгән 50 дән артык кеше таралышып бетте. Раянның кабере янында Гөлфия белән Миләүшә генә калдылар. Кабере өстенә яткан әнисенең күз яше инде таммый. Иң соңгы булып төшкән яшь бөртеге Гөлфия утырткан яран гөлгә төште. Шул чак ул күзләрен күтәрде дә каядыр билгесезлеккә төбәлеп: “Каһәр суккан сугыш! Каһәр суккан кешеләр! Каһәр суккан ил!” Бер-ике секунда пауза ясап дәвам итте, әмма бер җөмлә генә өстәде: “Минем улымны шул утка салганнары өчен үзләрен каһәр суксын... җир йотсын!”

Раянның кырыгын үткәргән көнне Фәрит гаиләсе белән машина авариясенә эләкте. Үзе комада ята, ә хатыны белән улын коткара алмадылар.

Бер айдан Фәрит хатыны һәм улы кабере янына килде. Хәзер көч-хәл белән йөрүче бу кеше үзенең яшәү мәгънәсен тулысынча югалтканына төшенде. Авыртуларга түзеп, ул күзләрен агып баручы куе болытларга күтәрде. Шулар белән бергә тормышы үтеп баруын сизде. Гомер буе ул тормыш куды, нидер тапты, гел беренче булырга күнегеп китте. Гөлфияне дә ул үз сүзен бирмәс өчен генә үзенеке итәсе килде. Болытлар бу серне ачты шикелле. Тик менә хәзер, гаиләсен югалткач, үзе дә инвалид булып калгач, баштарак табылган акчасының, дәрәҗәсенең мәгънәсе калдымы соң? Шул ук вакытта улының кабере янында тезләнеп торган Гөлфия дә каядыр агылучы болытларга карый иде.

Ике ялгыз кешенең башында бер үк уй чуалды: “Бу агымсудай тормышта бер-береңә “яратам”, “гафу ит” дияргә кайвакыт бер гомер аз була икән...”